**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР — ПОСТАНОВЛЕНИЕ

от 26.06.2020 — № ПР-132

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "ЗӨБӘЕР ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ "ТҮКЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘСЕН БЕТЕРҮ ТУРЫНДА

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61-64 статьяларына, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 29.12.2012 ел, №273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына, 2020 елның 25 июнендә кабул ителгән Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең 23 нче бәяләмәсе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Түке авылы гражданнар җыелышының 18.06.2020 беркетмәсе нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреҗдениесенең “Түке балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсен 29.06.2020 елдан бетерергә.

2. " Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Р.А.Госмановага:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреҗдениесе Уставына үзгәрешләр проектын әзерләргә;
- хезмәт законнары нигезендә бетерелә торган мәгариф учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;
- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Зөбәер төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреҗдениесенең “Түке балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсен закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә бетерергә.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Руководитель — И.И. Габдулхаев